КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 декабрь г.Казань № 1233

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карары белән расланган 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 июль, 548 нче; 2015 ел, 26 май, 378 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1024 нче; 2016 ел, 30 сентябрь, 697 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1082 нче; 2018 ел, 26 апрель, 298 нче һәм 2019 ел, 28 март, 227 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="3">«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>Программаны финанслау күләме 4 522,8 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән 2 044,9 млн.сумы – федераль бюджет акчасы, 2 342,1 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 135,8 млн.сумы – бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән.<br>(млн.сум)</td></tr>
<tr><td>

| Ел | Программа буенча финанслау күләме барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе бюджеты акчасы | Җирле бюджет акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклар акчасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2013 | | | | | |
| 2014 | 46,2 | 9,9 | 36,3 | | |

</td></tr>
</table>

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2015 | 136,4 | 84,6 | 51,8 | | |
| | 2016 | 1 203,5 | 625,2 | 442,5 | | 135,8 |
| | 2017 | 1 411,3 | 524,3 | 887,0 | | |
| | 2018 | 1 610,6 | 1 092,4 | 518,2 | | |
| | 2019 | 114,8 | 5,7 | 109,1 | | |
| | Бар-лыгы | 4 522,8 | 2 342,1 | 2 044,9 | | 135,8»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «III. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕН НИГЕЗЛӘҮ

Программаны финанслау күләме 4 522,8 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән 2 044,9 млн.сумы – федераль бюджет акчасы, 2 343,1 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 135,8 млн.сумы – бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән.

(млн.сум)

| Ел | Программа буенча финанслау күләме барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федера-циясе бюджеты акчасы | Җирле бюджет акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклар акчасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2013 | | | | | |
| 2014 | 46,2 | 9,9 | 36,3 | | |
| 2015 | 136,4 | 84,6 | 51,8 | | |
| 2016 | 1 203,5 | 625,2 | 442,5 | | 135,8 |
| 2017 | 1 411,3 | 524,3 | 887,0 | | |
| 2018 | 1 610,6 | 1 092,4 | 518,2 | | |
| 2019 | 114,8 | 5,7 | 109,1 | | |
| Барлыгы | 4 522,8 | 2 342,1 | 2 044,9 | | 135,8 |

Программаның фаразлана торган ресурслар белән тәэмин ителеше аңа теркәлгән 1 нче кушымтада бирелә.»;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин